КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 февраль г.Казань № 67

2020-2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге затларны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын гамәлгә ашыру чаралары турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 298 карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карарын, «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм тормыш сыйфатын күтәрү программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру (Өлкән буын)» федераль проектын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы яки эш эзләүче һәм 2020 – 2022 елларда халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия яше алдындагы затларны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын оештыру өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге затларны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын гамәлгә ашыруга бәйле «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу

максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибе;

2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге хезмәткәрләргә һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын тормышка ашыру өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә субсидияләр бирү тәртибе;

2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге хезмәткәрләренә һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын оештыру тәртибе;

2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге эш эзләүче гражданнарга һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын оештыру тәртибе.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2019 – 2021 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында пенсия алды яшендәге затларны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү чараларын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2019 ел, 4 апрель, 272 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2021 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында пенсия алды яшендәге затларны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү чараларын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2019 ел, 4 апрель, 272 нче карары белән расланган 2019 – 2021 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында пенсия алды яшендәге эш эзләүче гражданнарны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү чараларын оештыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2019 ел, 09 сентябрь, 806 нчы.

3. Әлеге карар белән расланган тәртипләрне куллану буенча аңлатмалар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 3 февраль, 67 нче
карары белән расланды

2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге затларны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын гамәлгә ашыруга бәйле «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану
тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы яки эш эзләүче һәм эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать итүче 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк затларны, шулай ук пенсия алды яшендәге затларны һөнәри укытуга һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын гамәлгә ашыруга бәйле «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган төбәк проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия (алга таба – субсиди) рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану механизмын билгели.

2. Субсидия Татарстан Республикасы бюджеты акчалары белән операцияләрне исәпкә алу өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә ачылган Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе (алга таба – Казначылык) хисабына керә.

3. Агымдагы финанс елында бүтән бюджетара трансфертны тоту әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә агымдагы финанс елына гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылыктан бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бүтән бюджетара трансфертны финанслауның иң чик күләмнәре турында мәгълүмат алынганнан соң җиде эш көне эчендә агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) бүтән бюджетара трансфертны финанслауның иң чик күләмнәрен җиткерә.

5. Министрлык Татарстан Республикасы Финанс министрлыгыннан агымдагы финанс елына бүтән бюджетара трансфертны финанслауның иң чик күләме турында мәгълүмат алганнан соң җиде эш көне эчендә агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренә (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре) агымдагы финанс елына

Министрлык тарафыннан билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә финанслауның чик күләмнәрен җиткерә.

6. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре агымдагы финанс елына билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә һәм аларның счетларына акча кергән саен:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган 2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк хезмәткәрләргә, шулай ук пенсия алды яшендәге хезмәткәрләргә һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча чараларны тормышка ашыруга юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә субсидияләр бирү тәртибе нигезендә субсидияләр рәвешендә акчаларны юридик затлар (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш), шәхси эшмәкәрләр счетларына күчерәләр;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган 2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында пенсия алды яшендәге хезмәткәрләргә һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча чараларны тормышка ашыруга Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә субсидияләр бирү тәртибе һәм 2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында пенсия алды яшендәге эш эзләүче гражданнарга һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча чараларны тормышка ашыруга Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә субсидияләр бирү тәртибе нигезендә «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә төзелгән дәүләт контрактлары (килешүләр) нигезендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар хезмәтләре өчен түлиләр.

7. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 11 числосыннан да соңга калмыйча Министрлык билгеләгән формалар буенча Министрлыкка, аларны финанслашу максатларында бүтән бюджетара трансфертлар бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында, бүтән бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләренең әһәмиятенә ирешү турында хисап тапшыралар.

Министрлыкка тапшырылган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә йөкләнә.

8. Министрлык билгеләнгән вакытта Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү буенча федераль хезмәткә Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү буенча федераль хезмәт һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында 2019 елның 13 декабрендәге 150-09-2020-205 номерлы 50 яшь һәм аннан өлкәнрәк затларны, шулай ук пенсия алды яшендәге номерлы затларны һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем алуга юнәлдерелгән Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидия бирү турындагы килешүгә кушымталар нигезендә формалар буенча хисап тапшыра.

Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү буенча федераль хезмәткә тапшырыла торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык Министрлыкка йөкләнә.

9. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына кергән бүтән бюджетара трансферттан максатсыз файдалану Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

10. Хисап елыннан соң килүче финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый торган бүтән бюджетара трансферт калдыклары Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

11. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту Министрлык һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 3 февраль, 67 нче
карары белән расланды

2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге хезмәткәрләргә һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын тормышка ашыру өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә субсидияләр бирү тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1. 2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге хезмәткәрләргә һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын тормышка ашыру өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә субсидияләр бирү тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 298 номерлы карары нигезендә эшләнгән.

2. Әлеге Тәртип максатлары өчен кулланыла торган төшенчәләр:

оешмалар – юридик затлар (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш), шәхси эшмәкәрләр;

халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре – Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре;

хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы пенсия яшендәге затлар – картлык буенча иминият пенсиясен, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган, алу хокукы бирә торган яшькә җиткәнче биш ел дәвамында оешма хезмәткәрләре;

хезмәткәрне пенсия алды яшендәге гражданнар категориясенә кертүне раслаучы документ – Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органы биргән белешмә яки әлеге органның конкрет граждан буенча оешма, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге соратуына уңай җавабы.

3. 2020 – 2022 елларда «Демография» милли проектының «Өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм тормыш сыйфатын күтәрү программасын эшләү һәм тормышка ашыру (Өлкән буын)» федераль проекты кысаларында 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге затларга һөнәри белем бирүне һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру (алга таба – укыту) чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бүтән бюджетара трансфертлар исәбеннән субсидияләр (алга таба – субсидияләр) Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» дәүләт программасы (алга таба – Дәүләт программасы) нигезендә «Өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм тормыш сыйфатын күтәрү программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру (Татарстан Республикасы (Татарстан))» төбәк проекты (алга таба – «Өлкән буын» төбәк проекты) кысаларында әлеге оешмалар белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы пенсия алды яшендәге затларны укыту буенча чараларны тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында оешмаларга бирелә.

4. Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы тарафыннан билгеләнгән үрнәк форма нигезендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге һәм оешма арасында төзелә торган агымдагы елга субсидия бирү турында килешү нигезендә (алга таба – субсидия бирү турында килешү) Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчаларын алучылар буларак билгеләнгән тәртиптә тиешле финанс елына субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан оешмаларга субсидияләр бирелә.

5. Субсидияләр алу хокукына билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы, штатында Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия яшенә кадәрге затлар категориясенә караган хезмәткәрләр (алга таба – хезмәткәрләр) булган, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә әлеге Тәртипнең II бүлеге нигезендә гаризалар тапшырган оешмалар ия.

6. Килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче көненә субсидия алучылар туры килергә тиеш булган таләпләр:

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычлары юк;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән кире кайтару вакыты чыккан бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында кире кайтару буенча вакыты чыккан башка бурычлары юк;

юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында түгел, ә шәхси эшмәкәрләр шәхси эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмаган;

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булган чит ил юридик затларның катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артыграк булган Россия юридик заты түгел;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы түгел.

7. Хезмәткәрләрне укыту һөнәри белем бирүнең төп мәгариф программалары һәм һөнәри яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрүнең өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча гамәлгә ашырыла.

Хезмәткәрләрне укыту «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Һөнәри белем бирүнең төп программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 18 апрель, 292 нче, «Өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 499 нчы, «Һөнәри белем бирү гамәлгә ашырыла торган эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2013 ел, 2 июль, 513 нче боерыклары һәм мәгариф өлкәсендә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Укулар белем бирү эшчәнлеге гамәлгә ашыруга лицензиясе булган һөнәри белем бирүнең төп мәгариф программалары, өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда үткәрелә.

8. Агымдагы елда оешмаларга бирелә торган субсидияләрнең гомуми күләме тиешле елга Дәүләт программасының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм чараларын гамәлгә ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидлапрны озата бару» ярдәмче программасының 2 нче кушымтасындагы 8.1 пунктын үтәү өчен каралган акчаларның гомуми күләменнән артып китә алмый.

## II. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

9. Субсидия алу өчен оешма агымдагы елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча үзенең төп эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә агымдагы елга субсидия алу өчен кәгазьдә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча (алга таба – Министрлык) гариза (алга таба – гариза) тапшыра, анда түбәндәгеләр була:

а) әлеге Тәртипнең 13 пункты нигезендә җитештерелгән субсидия күләмен исәпләү;

б) түбәндәгеләр белән «Өлкән буын» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында элек белем алмаган, агымдагы елда укырга җибәрелүче хезмәткәрләр исемлеге күрсәтелгән:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

хосусый шәхси счетның иминият номеры;

туган көне;

хезмәткәрне пенсия алды яшендәге гражданнар категориясенә кертүне раслаучы документ реквизитлары;

эшче һөнәренең яисә соңгы эш урыны буенча хезмәткәр вазыйфасының исеме;

урта һөнәри яки югары белем булу турында мәгълүматлар;

хезмәткәрләрне укыту оештырылачак белем бирү программасының исеме.

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрының Язу бите (Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрының Язу бите) күчермәсе;

килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче көне торышына

килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче көненә торышына Россия Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче (җыю түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентларны түләү бурычларын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау турында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча белешмә;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән кайтару буенча вакыты чыккан бурычы һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында (ирекле формада), башка кичектерелгән бурычы булмавы турында оешма җитәкчесе һәм баш хисапчысы тарафыннан кул куелган, мөһере белән беркетелгән (мөһере булган очракта) белешмә;

юридик затның үзгәртеп кору, бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәвен, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын, шәхси эшмәкәр буларак шәхси эшмәкәр эшчәнлеге туктатылмавын раслый торган, оешма мөһере белән беркетелгән (мөһере булган очракта) җитәкче имзалаган белешмә;

оешма чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган (офшор зоналар) чит ил юридик затларының катнашуы өлеше тулаем алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик заты булмаганны раслый торган, оешма мөһере белән беркетелгән (мөһере булган очракта) җитәкче имзалаган белешмә;

оешманың Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар нигезендә акча алучы булып тормавын раслый торган, җитәкче һәм баш хисапчы имзалаган, оешманың мөһере белән (мөһере булган очракта) беркетелгән белешмә.

10. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге:

гариза кергән көнне, аның керү датасын һәм вакытын күрсәтеп һәм гаризага теркәүнең тәртип номерын биреп, гаризаны терки;

Министрлык кушуы буенча субсидия бирү турында оешма белән шартнамә төзү турында яки субсидия бирү турында оешма белән шартнамә төзүдән баш тарту турында карар кабул итү максатларында теркәлгән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә керү чиратына ярашлы рәвештә әлеге Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килүгә гаризаны карап тикшерә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан агымдагы елның 1 декабреннән соң тәкъдим ителгән гаризалар кабул ителми һәм карап тикшерелми.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан элек теркәлгән гаризалар буенча кергән гаризалар каралмый, аларның үтәлеше әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары суммасы төгәлләнә, һәм мондый гаризалар кергән көнне түбәндәге оешмалар өч эш көне эчендә кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, гаризаны кире кагу турында язма хәбәр җибәрелә.

Оешмаларга гаризалар кире кайтарылмый һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә билгеләнгән тәртиптә саклана.

11. Субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

оешма тарафыннан әлеге Тәртипнең 9 пунктында күчерелгән документларны тапшырмау (тапшыру тулы күләмдә булмау);

оешма тарафыннан әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән гаризада һәм документларда күрсәтелгән мәгълүматның дөрес булмавы;

оешма тәкъдим иткән гаризаның әлеге Тәртипнең 9 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

оешманың әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

агымдагы финанс елына субсидия бирү өчен халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын оештыру тарафыннан гариза биргән датага бетерү.

12. Субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарту өчен нигез булмаган очракта, гариза карап тикшерү тәмамланган көннән соң килүче эш көне дәвамында оешма белән субсидия бирү турында килешү төзү турында карар кабул итә һәм оешмага ике нөсхәдә субсидия бирү турында килешү проектын теркәп, кабул ителгән карар турында язмача хәбәр җибәрә.

Субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, гариза карап тикшерү тәмамланган көннән соң килүче эш көне дәвамында оешма белән субсидия бирүдән баш тарту турында килешү төзү турында карар кабул итә һәм оешмага ике нөсхәдә субсидия бирү турында килешү проектын теркәп, кабул ителгән карар турында язмача хәбәр җибәрә.

13. Агымдагы елда оешмага бирелә торган субсидия күләме ($S_{обуч}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_{обуч} = N_р \times C_{обуч} + N_{рпер} \times (R_{пр} + C_{обуч} + P_{обуч} \times (R_{сут} + R_{рн})),$$

монда:

$N_р$ – яшәү төбәгендә белем алырга ниятләнгән хезмәткәрләрнең фаразланган саны, кеше;

$N_{рпер}$ – башка урында белем алырга ниятләнгән хезмәткәрләрнең фаразланган саны, кеше;

$C_{обуч}$ – бер кешегә белем бирү курсының уртача бәясе, сум;

$P_{обуч}$ – белем бирүнең уртача чоры;

$R_{пр}$ – белем алырга башка урынга бару һәм кире кайту бәясен һәм багаж ташу бәясен факттагы чыгымнарны компенсацияләүгә чыгымнар, ләкин тимер юл

транспортында пассажирлар йөртү өчен каралган тарифлардан югарырак булмаган күләмдә (10 000 сумнан да артмаган);

$R_{сут}$ – башка җирлектә бер айга тәүлеклек уку өчен түләү чыгымнары 3 000 сумга (30 көн дәвамында тәүлегенә 100 сум исәбеннән);

$R_{рн}$ – бер ай дәвамында башка җирдә булган вакытта торак урыны наймы буенча чыгымнар 33 000 сумнан да артмый (30 көн дәвамында тәүлегенә 1 100 сумнан да артмый).

Хезмәткәрне укыту бәясенә белем бирү эшчәнлеген, махсус кием, махсус аяк киеме һәм башка шәхси саклану чараларын гамәлгә ашыручы оешмалар хезмәтләре өчен түләү чыгымнарының бәясе кертелә (кирәк булганда).

14. Субсидия бирү турындагы килешүдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидия алучы тарафыннан кире кайтару очраклары һәм тәртибе, югары технологияле чит ил җиһазларын, чималны һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (җибәргәндә) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук субсидияләр бирү максатларына ирешүгә бәйле башка операцияләрдән тыш, чит ил валютасы акчалары хисабына сатып алуны тыю, субсидияләр бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең мәгънәсе, әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында һәм әлеге Тәртипнең 13 пунктындагы алтынчы абзацында күрсәтелгән чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап алучы тарафыннан хисап бирү тәртибе, сроклары һәм формалары, шул исәптән субсидия алучының субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән срокларны халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә хезмәткәрләрне укыту буенча чаралар үткәрүне раслаучы документларны бирү бурычы (хезмәткәрләрне укытуның башлануы һәм тәгәлләнүе турында приказлар, квалификация турында документлар, дәресләргә йөреш табельләре күчермәләре, билгеләнгән тәртиптә расланган укыту-программа документлары күчермәләре), субсидия алучының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык, дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне тормышка ашыруга ризалыгы (устав (җыелма) капиталларында җәмәгать-хокукый берәмлекләр катнашкан дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр, хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләреннән, шулай ук устав җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашкан коммерциячел оешмалардан тыш), субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртип шартларын һәм субсидия бирү турында төзелә торган шартнамә үтәлеше турында нигезләмәләр, субсидия бирү турында килешү шартларын бозган өчен җаваплылык карала.

15. Оешма халыкны эш белән тәэмин итү үзәге субсидия бирү турында килешү проектын алган көннән алып проектын эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә ике нөсхәдә субсидия бирү турында килешүгә имза куя һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшыра.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге оешмадан субсидия бирү турында төзелгән килешүне алган көннән соң бер эш көне эчендә әлеге килешүгә кул куя һәм субсидия бирү турында яклар тарафыннан имзаланган килешүнең бер нөсхәсен оешмага җибәрә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакыт эчендә оешма тарафыннан имзаланган субсидия бирү турында килешү халыкны эш белән тәэмин

итү үзәгенә күрсәтелмәгән очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге вакыт үткәннән соң ике эш көне эчендә оешма белән субсидия бирү турында килешү төзү карарын гамәлдән чыгара һәм әлеге карарны гамәлдән чыгару сәбәпләрен күрсәтеп оешмага хәбәрнамә җибәрә.

16. Оешмага субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

һөнәри белем алган яки өстәмә һөнәри белем алган хезмәткәрләр саны;

һөнәри белем алган яки өстәмә һөнәри белем алган хезмәткәрләр санында эш белән тәэмин ителгәннәр өлеше.

Субсидия алучы халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тәкъдим итә:

әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча, хисап аеннан соң килүче айның 5 числосына кадәр, ай саен, үсә барган йомгак белән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап;

субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән срокларда һәм форма буенча, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап.

17. Оешма тарафыннан субсидия бирү турында килешүдә күрсәтелгән максатларга субсидияләр сарыф итүне раслый торган документлар, шул исәптән оешма һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма(-лар) арасында килешү(-ләр) яки оешма тарафыннан расланган хезмәткәрләрне укыту чараларын тормышка ашыру өчен чыгымнар сметасын тапшырганнан соң, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге үзенең счетына акча кергән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә субсидияне оешманың Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган хисап счетына күчерә.

Әгәр оешма субсидия бирү турында килешү төзелгән көннән соң җиде эш көне эчендә әлеге пунктның беренче абзацында каралган документларны халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырмаган булса, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге берьяклы тәртиптә субсидия бирү турында килешү өзә һәм оешмага әлеге килешүне өзү нигезләре һәм субсидияләр бирү буенча хокук мөнәсәбәтләрен (субсидия күчерүне) туктату турында хәбәрнамә җибәрә.

Оешма субсидия керү һем чыгымнары буенча аерым бухгалтерия исәбен алып бара.

18. Хезмәткәрләрне укытуны оештыру, укыту чыгымнары бәясенең нигезле булуын исәпкә алып, мөстәкыйль гамәлгә ашырыла.

## III. Йомгаклау нигезләмәләре

19. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия субсидия алучыларга халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге һәм дәүләт финанс контроле органы субсидия алучылар тарафыннан субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

20. Бирелгән субсидияләр халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең тиешле таләбе алынган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан

Республикасы бюджетына субсидия алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган аларны күрсәткәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта тулы күләмдә;

субсидияне максатчан файдаланмау ачыкланган очракта – максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган субсидия күләмендә.

21. Субсидия алучы тарафыннан агымдагы елның 31 декабренә әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү буенча йөкләмәләр бозылган очракта һәм субсидия бирелгән елдан соң килүче елда субсидия бирү турында килешү нигезендә әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәсенә ирешү турында хисап тапшыруның беренче көненә кадәр күрсәтелгән бозулар бетерелмәсә, Татарстан Республикасы бюджетына субсидия бирү елыннан соң килүче елның 1 апреленә кадәр кире кайтарылырга тиешле акчалар күләме ($V_{возврата}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V_{возврата} = (V_{субсидии} \times k \times \frac{m}{n}) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидии}$ – хисап финанс елында субсидия алучыга бирелгән субсидия күләме;

k – субсидияне кире кайтару коэффициенты;

m – субсидияләр бирү нәтиҗәлелеге күрсәткече саны, алар буенча субсидия бирү нәтиҗәлелегенең *i* күрсәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган индекс уңай мәгънәгә ия;

n – субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең гомуми саны.

Субсидияне кире кайтару коэффициенты (k) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$k = SUM\frac{D_i}{m},$$

монда $D_i$ – субсидия бирү нәтиҗәлелегенең *i* күрсәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган индекс.

Субсидияне кире кайтару коэффициентын исәпләгәндә субсидия бирү нәтиҗәлелегенең *i* күрсәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган индексның уңай мәгънәләре генә кулланыла.

Субсидия бирү нәтиҗәлелегенең *i* күрсәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган индекс ($D_i$) фактта ирешелгән мәгънәгә ия булган нәтиҗәлелек күрсәткечләре өчен субсидияләр куллануның зур нәтиҗәлелеген чагылдыра торган түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$D_i = 1 - \frac{T_i}{S_i},$$

монда:

$T_i$ – хисап датасына субсидия бирү нәтиҗәлелегенең *i* күрсәткеченең фактта ирешелгән мәгънәсе;

$S_i$ – субсидияләр бирү нәтиҗәлелегенең килешү нигезендә билгеләнгән *i* күрсәткеченең план мәгънәсе.

22. Субсидия бирү турында килешүдә каралган очракларда субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше хисап елыннан соң килүче финанс елында, оешма хезмәткәрләрен укыту вакыты тәмамланганнан соң 30 көн эчендә, әмма хисап елыннан соң килүче финанс елының 1 апреленнән дә соңга калмыйча, субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

23. Әлеге Тәртипнең 20 – 22 пунктларында каралган очракларда, субсидия алучы күрсәтелгән пунктлар белән билгеләнгән акчаларны ирекле кире кайтару вакытын бозганда, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге вакыт узганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә әлеге акчаларны законда билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрә. Бу чакта субсидия алучы субсидия алган көннәе соң килүче көннән башлап аны кире кайтару көнен кертеп, акчаны кире кайтармаган һәр көн өчен бурыч суммасыннан 0,03 процент күләмендә пеня түли.

24. Оешмалар халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.

2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге хезмәткәрләргә һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын тормышка ашыру өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә субсидияләр бирү тәртибенә кушмта

Форма

20__ елның ________________
субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап

Субсидия алучы исеме: _________________________________.
Кабатлануы: ел саен, хисаптан соң килүче айның 5 числосына кадәр.

| Т/б № | Нәтиҗә атамасы | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең пландагы әһәмияте | Хисап датасына ирешелгән нәтиҗә күрсәткече | Планны үтәү проценты | Кире кагуның сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | код | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

Җитәкче
(вәкаләтле зат) ______________ ____________ _________________________________
(вазыйфа) (имза) (имза аңлатмасы)

Исполнитель ____________ ___________ ________________________ ______________
(вазыйфа) (имза) (имза аңлатмасы) (телефон)

«__» _________ 20__ ел

_________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 3 февраль, 67 нче
карары белән расланды

## 2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге хезмәткәрләренә һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын оештыру тәртибе

1. 2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге хезмәткәрләренә һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын оештыру тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 298 номерлы карары нигезендә эшләнгән.

2. Әлеге Тәртип максатлары өчен кулланыла торган төшенчәләр:

учреждениеләр – дәүләт (муниципаль) учреждениеләре;

халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре – Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре;

хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы пенсия яшендәге затлар – картлык буенча иминият пенсиясен, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган, алу хокукы бирә торган яшькә җиткәнче биш ел дәвамында оешма хезмәткәрләре;

хезмәткәрне пенсия алды яшендәге гражданнар категориясенә кертүне раслаучы документ – Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органы биргән белешмә яки әлеге органның конкрет граждан буенча оешма, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге соратуына уңай җавабы.

3. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре 2019-2021 елларда тиешле елга бүлеп бирелгән «Демография» милли проектының «Өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм итү һәм тормыш сыйфатын күтәрү программасын эшләү һәм тормышка ашыру (Өлкән буын)» федераль проекты кысаларында 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге затларны укытуны оештыру чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар исәбеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэминителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасы нигезендә «Өлкән буын

гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм тормыш сыйфатын күтәрү программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру (Татарстан Республикасы (Татарстан)» төбәк проекты (алга таба – «Өлкән буын»төбәк проекты) кысаларында учреждениеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы пенсия яшенә кадәрге затларга (алга таба – хезмәткәрләр) һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча чараларны (алга таба – укыту) тормышка ашыруны оештыра.

4. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән чараларда катнашу хокукына билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә әлеге Тәртип нигезендә гаризалар биргән учреждениеләр ия.

5. Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчаларын алучылар буларак билгеләнгән тәртиптә хезмәткәрләрне тиешле финанс елына укыту чараларын гамәлгә ашыруга бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хезмәткәрләрне укытуны оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар белән дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзүне гамәлгә ашыра.

6. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) раслаган үрнәк форма нигезендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән учреждение арасында төзелгән агымдагы елга учреждение хезмәткәрләрен укыту буенча чараларны гамәлгә ашыру турында килешү (алга таба – килешү) нигезендә хезмәткәрләрне укыту чараларын гамәлгә ашыра.

7. Хезмәткәрләрне укыту һөнәри белем бирүнең төп мәгариф программалары һәм һөнәри яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү программалары буенча өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча гамәлгә ашырыла.

Хезмәткәрләрне укыту «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Һөнәри белем бирүнең төп программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 18 апрель, 292 нче, «Төп һөнәри белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 499 нчы, «Һөнәри белем бирү гамәлгә ашырыла торган эшче һөнәрләр, хезмәткәрләр вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2013 ел, 2 июль, 513 нче карарлары һәм мәгариф өлкәсендә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Укулар мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, һөнәри белемнең төп белем бирү программалары, өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган оешмаларда үткәрелә.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр исәбеннән башка җирлектәге учреждениеләр хезмәткәрләрен укыту очрагында чыгымнар түләнә:

башка җирлеккә уку урынына бару һәм кире кайту һәм фактик чыгымнар күләмендә багаж алып бару, әмма тимер юл транспортында пассажирлар йөртү өчен каралган тарифлардан югарырак түгел (учреждение буенча уртача 10 000 сумнан да артык түгел);

башка җирлектә уку чорында тәүлеклеклек түләү, тәүлегенә 100 сум исәбеннән;

уку чорында башка җирдә булган вакытта торак урыны наемы учреждение буенча уртача тәүлегенә 1100 сумнан да артмый.

8. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән чараларда катнашу өчен учреждение агымдагы елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә үзенең төп эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча агымдагы елга килешү төзүгә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча агымдагы елда укуларга җибәрелә торган хезмәткәрләрнең исемлекләрен үз эченә алган кәгазь чыганакта күрсәтелгән гариза (алга таба – гариза) тапшыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

шәхси исәп-хисап счетының иминиятләү номеры;

туган көне;

хезмәткәрне пенсия алды яшендәге гражданнар категориясенә кертүне раслый торган документ реквизитлары (50 яше тулмаган, оешма белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы пенси алды яшендәге затлар өчен);

соңгы эш урыны буенча эшче һөнәренең яисә хезмәткәрләрнең соңгы эш урыны буенча биләгән вазыйфасы исеме;

урта һөнәри яки югары белем булу турында мәгълүматлар;

хезмәткәрләрне укыту оештырылачак белем бирү программасының исеме.

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында Язылу битенең күчермәсе;

учреждение үзгәртеп кору, бетерү процессында булмавын раслый торган, учреждение җитәкчесе имза куйган һәм мөһере белән беркетелгән (булганда) белешмә.

9. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге:

гариза кергән көнне аның керү датасын һәм вакытын күрсәтеп һәм гаризага теркәлүнең тәртип номерын биреп, гаризаны терки;

теркәлгән документлары белән гаризаны әлеге Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килү чираты нигезендә, теркәлгән көннән алып килешү төзү яки килешү төзүдән баш тарту турында карар кабул итү максатларында, эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә карап тикшерә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан агымдагы елның 1 декабреннән соң тәкъдим ителгән гаризалар кабул ителми һәм карап тикшерелми.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан элек теркәлгән гаризалар буенча карарлар кабул ителгәннән соң кергән гаризалар каралмый, аларның үтәлеше белән әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары суммасы төгәлләнә, һәм әлеге гариза кергән көннән соң килүче өч эш көне эчендә

учреждениегә кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, гаризаны кире кагу турында язма хәбәр җибәрелә.

Учреждениеләргә гаризалар кире кайтарылмый һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә билгеләнгән тәртиптә саклана.

10. Килешү төзүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

учреждение тарафыннан әлеге Тәртипнең 8 пунктында күчерелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

учреждение тарафыннан әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән гаризада һәм документларда күрсәтелгән мәгълүматның дөрес булмавы;

учреждение тәкъдим иткән гаризаның әлеге Тәртипнең 8 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

учреждениенең әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән шартларга туры килмәве.

11. Килешү төзүдән баш тарту өчен нигез булмаган очракта халыкны эш белән тәэмин итү үзәге гаризаны карап тикшерү вакыты тәмамланган көннән соң килүче эш көне дәвамында килешү төзү турында карар кабул итә һәм килешү проектын ике нөсхәдә теркәп, учреждениегә кабул ителгән карар турында язмача хәбәр җибәрә.

Килешү төзүдән баш тарту өчен нигез булган очракта халыкны эш белән тәэмин итү үзәге гаризны карап тикшерү вакыты тәмамланган көннән соң килүче эш көне дәвамында килешү төзүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, учреждениегә кабул ителгән карар турында язмача хәбәр җибәрә.

12. Учреждение халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан килешү проектын алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә килешү төзи һәм аны ике нөсхәдә халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тәкъдим итә.

Учреждениедән имзаланган килешү алган көннән соң килүче бер эш көне эчендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге килешүгә кул куя һәм яклар тарафыннан имзаланган килешүнең бер нөсхәсен учреждениегә җибәрә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакытта учреждение тарафыннан имзаланган килешүне учреждение халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырмаган очракта, әлеге вакыт үткәннән соң ике эш көне эчендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге килешү төзү турындагы карарны гамәлдән чыгара һәм учреждениегә әлеге карарны гамәлдән чыгару сәбәпләрен күрсәтеп, гамәлдән чыгару турында хәбәр җибәрә.

13. Пенсия алды яшендәге затларны «Өлкән буын» төбәк проекты кысаларында һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын гамәлгә ашыру кысаларында кабат укыту рөхсәт ителми.

Уку чорында 50 яшькә җитмәгән һәм хезмәткәрләр категориясенә керә торган хезмәткәрләрне картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә кадәр биш ел дәвамында укыту картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә кадәр тәмамланырга тиеш.

14. Хезмәткәр укуны тәмамлагач учреждение укуның соңгы көне булган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә халыкны эш белән тәэмин итү

үзәгенә учреждениедә хезмәткәрнең эш урынын саклап калуны яки башка эш урынына күчерүне раслаучы, яки хезмәткәрне башка оешмага эшкә урнаштыру документларының таныкланган күчермәләрен тәкъдим итә.

15. Хезмәткәр белем ала башлаганнан бирле, килешү нигезендә һәм хисап елыннан соң килүче елның беренче кварталы тәмамланганчы, учреждение хезмәткәрләре санын яки штатын кыскартуга бәйле рәвештә, хезмәткәрләр белән хезмәт килешүләрен өзәргә ярамый.

16. Учреждениеләр халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырылган мәгълүматларның Россия Федерациясе законнары нигезендә дөреслеге өчен җаваплы.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 3 февраль, 67 нче
карары белән расланды

2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге эш эзләүче гражданнарга һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын оештыру
тәртибе

1. 2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында 50 яшьтәге һәм өлкәнрәк, шулай ук пенсия алды яшендәге эш эзләүче гражданнарга һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын оештыру тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 298 номерлы карары нигезендә эшләнгән.

2. Әлеге Тәртип максатлары өчен кулланыла торган төшенчәләр:

пенсия алды яшендәге гражданнар – картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасында теркәлгән, эш эзләүче һәм мөстәкыйль рәвештә халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына һөнәри белем алу һәм (яки) өстәмә һөнәри белем алу максатыннан мөрәҗәгать иткән гражданнар;

халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре – Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре;

эш эзләүче гражданның пенсия яшенә кадәрге гражданнар категориясенә кертелүен раслаучы мәгълүмат – халыкны эш белән тәэмин итү үзәге соратуына конкрет гражданның пенсия алды яшендәге гражданнар категориясенә керүен билгеләү максатларында мөрәҗәгатенә Россия Федерациясе Пенсия фонды территориаль органының уңай җавабы.

3. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре 2020 – 2022 елларда Татарстан Республикасы бюджеты һәм федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына 50 яшь һәм аннан өлкәнрәк затларга, шулай ук пенсия алды яшендәге затларга тиешле елга бүлеп бирелгән «Демография» милли проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында укытуны оештыру чараларын гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын (алга таба – дәүләт программасы) раслау турында» 2013 ел, 9

август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» дәүләт программасына (алга таба – дәүләт программасы) ярашлы рәвештә, «Демография» милли проекты составына керүче «Өлкән буын» федераль проектының максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин иткән «Өлкән буын гражданнарына (Татарстан Республикасы) системалы ярдәм һәм тормыш сыйфатын күтәрү программасын эшләү һәм тормышка ашыру» төбәк проекты (алга таба – «Өлкән буын» төбәк проекты) кысаларында 50 яшь һәм аннан өлкәнрәк, шулай ук эш эзләүче һәм эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән пенсия алды яшендәге затларга һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирү (алга таба – уку) чараларын тормышка ашыруны оештыралар.

4. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән чараларда катнашу хокукына 50 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнар, шулай ук яшәү урыны буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә тиешле эш эзләү максатларында теркәлгән һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан расланган формада гариза белән мөрәҗәгать иткән пенсия алды яшендәге гражданнар (алга таба – гражданнар) ия.

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

50 яшькә яки аннан өлкәнрәк яшькә җитүне раслаучы документ күчермәсе (50 яшькә җитмәгән пенсия алды яшендәге гражданнар категориясенә керми торган гражданнар өчен);

индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ күчермәсе;

мәгариф турында документлар, мәгариф турында һәм квалификация турында документлар, квалификация турында документлар (булганда) күчермәсе;

хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (булган очракта) һәм (яки) тиешенчә таныкланган кәгазьдә яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат (булган очракта).

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге:

гаризага керү датасын һәм вакытын күрсәтеп, гаризага теркәлүнең тәртип номерын күрсәтеп, гариза кергән көнне аны терки;

әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килү чираты нигезендә, теркәлү көненнән башлап эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә гражданин тарафыннан бирелгән гаризаны һәм документларны карый.

Гражданнарга гаризалар кире кайтарылмый һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә билгеләнгән тәртиптә саклана.

5. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре эш эзләүче гражданны пенсия алды яше категориясенә кертүне раслый торган мәгълүмат нигезендә гражданның пенсия алды яшендәге гражданнар категориясенә керүен билгели.

6. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, Министрлык тарафыннан расланган типлаштырылган форма нигезендә, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге һәм граждан арасында төзелә торган агымдагы елга укуны оештыру турында килешү нигезендә (алга таба – килешү), гражданнарны укыту буенча чараларны гамәлгә ашыралар, анда халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан гражданны

укыту өчен белем бирү программасы исеме билгеләнә, гражданны эш белән тәэмин итү, эшкә урнаштыру, саклау һәм тәэмин итү өлешендә йөкләмә карала.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең килешү төзүдән баш тартуы өчен нигез булып тора:

әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документларны граждан тарафыннан тапшырмау (тапшыру тулы күләмдә түгел);

граждан биргән мәгълүматның дөрес булмавы;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән чараларда агымдагы елда яки алдагы елларда катнашу;

әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары суммасын бетерү.

Килешү төзүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көне эчендә килешү төзү турында карар кабул итә һәм гражданга килешү проекты кушып кабул ителгән карар турында ике нөсхәдә язмача хәбәр җибәрә.

Килешү төзүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көне эчендә килешү төзүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм гражданга кабул ителгән карар турында, сәбәпләрен күрсәтеп, язмача хәбәр җибәрә.

Граждан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге җибәргән килешү проекты алганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә нөсхәдә килешү имзалый һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшыра.

Граждан кул куелган килешүне алганнан соң бер эш көне эчендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге килешүгә кул куя һәм яклар тарафыннан имзаланган килешүнең бер нөсхәсен гражданга җибәрә.

Әлеге пунктның тугызынчы абзацында күрсәтелгән срокта граждан тарафыннан имзаланган килешү халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырылмаган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге вакыт узганнан соң ике эш көне эчендә килешү төзү турында карарны юкка чыгара һәм гражданга, әлеге карарны гамәлдән чыгару сәбәпләрен күрсәтеп, юкка чыгару турында хәбәрнамә җибәрә.

7. Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчаларын алучылар буларак билгеләнгән тәртиптә хезмәткәрләрне тиешле финанс елына укыту чараларын гамәлгә ашыруга бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хезмәткәрләрне укытуны оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар белән дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзүне гамәлгә ашыра

8. Гражданнарны укыту һөнәри белем бирүнең төп программалары һәм һөнәри яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү буенча өстәмә һөнәри программалар буенча эшкә урнаштыру (хезмәт эшчәнлеген дәвам итү) максатларында гамәлгә ашырыла.

Гражданнарны укыту «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф

һәм фән министрлыгының «Һөнәри белем бирүнең төп программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 18 апрель, 292 нче, «Өстәмә һөнәри программалар буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 499 нчы, «Һөнәри белем бирү гамәлгә ашырыла торган эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2013 ел, 2 июль, 513 нче боерыклары һәм мәгариф өлкәсендә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Укулар белем бирү эшчәнлеге гамәлгә ашыруга лицензиясе булган һөнәри белем бирүнең төп мәгариф программалары, өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда үткәрелә.

Татарстан Республикасы бюджеты һәм әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр исәбеннән башка җирлектәге учреждениеләр хезмәткәрләрен укыту очрагында чыгымнар түләнә:

башка җирлеккә уку урынына бару һәм кире кайту һәм фактик чыгымнар күләмендә багаж алып бару, әмма тимер юл транспортында пассажирлар йөртү өчен каралган тарифлардан югарырак түгел (10 000 сумнан да артык түгел);

башка җирлектә уку чорында тәүлеклеклек түләү, тәүлегенә 100 сум исәбеннән;

уку чорында башка җирдә булган вакытта торак урыны наемы учреждение буенча уртача тәүлегенә 1100 сумнан да артмый.

9. Пенсия алды яшендәге затларны «Өлкән буын» төбәк проекты кысаларында һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү чараларын гамәлгә ашыру кысаларында кабат укыту рөхсәт ителми.

Уку чорында 50 яшькә җитмәгән һәм хезмәткәрләр категориясенә керә торган хезмәткәрләрне картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә кадәр биш ел дәвамында укыту картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә кадәр тәмамланырга тиеш.

10. Дәүләт пенсия тәэминаты буенча пенсия алмаучы эшсез гражданнар укытуны оештыру кысаларында ай саен «Хезмәткә түләүнең минималь күләме турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләме күләмендә стипендия белән тәэмин ителә.

11. Гражданнар халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.